ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
УТАР-АТЫНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
*РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН*
ул.Кооперативная, д. 22, с. Утар-Аты,
Арский муниципальный район, 422017

*ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ*
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УТАР-АТЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Кооператив урамы, 22 йорт, Утар-Аты авылы,
Арча муниципаль районы, 422017

Тел. (84366)50-3-31, факс (84366)50-4-22. E-mail: Utat.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**« 2 » февраль 2021 ел** **№ 1**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы « Утар-Аты авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2021 елның 28 гыйнварындагы 73 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы « Утар-Аты авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләргә 1 нче һәм 2 нче кушымта нигезендә 6424 сум 98 тиен күләмендә бәя куярга һәм 2021 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Утар-Аты авыл җирлеге Башкарма комитетының "31" январь 2020 ел, № 3 "Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы « Утар-Аты авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында" карарын 2021 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Утар Аты авыл җирлеге башлыгы А.Г. Мөхәмәтгалиева

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Утар-Аты авыл җирлеге
Башкарма комитетының
" 2 "февраль 2021 ел, №1
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы « Утар-Аты авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләрнең БӘЯСЕ**

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4254,27 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка илтү | 513,78 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1656,93 |
| **Барлыгы** | **6424,98** |

Татарстан Республикасы
Арча муниципаль районы
Утар-Аты авыл җирлеге
Башкарма комитетының
" 2 "февраль 2021 ел, № 1
карарына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы « Утар-Аты авыл җирлеге » муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияле хезмәтләрнең**
**БӘЯСЕ**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәетне төрү | 231-19 |
| 3. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4023-08 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка илтү | 513-78 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү ) | 1656-93 |
| **Барлыгы** | **6424-98** |